КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 март г.Казань № 331

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк әһәмиятенә яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 сентябрь, 699 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләме күрсәткечләренә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк әһәмиятенә яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 сентябрь, 699 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 16 март, 192 нче; 2015 ел,

20 июнь, 445 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1147 нче; 2020 ел, 6 июль, 552 нче; 2022 ел, 1 апрель, 307 нче; 2022 ел, 2 август, 752 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләме күрсәткечләренә, искәрмәнең икенче абзацындагы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертү турында» 2022 ел, 7 март, 199 нчы карары нигезендә хәрәкәткә вакытлыча чикләү кертү чорында» сүзләрен «Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү гамәлдә булу чорында» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин